ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 12.11.2024 1774 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2023 елның 26 декабрендәге 2104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указының 2 пунктын үтәү йөзеннән, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2023 елның 26 декабрендәге 2104 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртинең 2.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.5. Түбәндәге категорияләрне бер тапкыр түләүсеә кайнар туклану белән тәэмин итәргә:
- 1-4 сыйныф укучы балаларын;
- дүрт һәм һәм аннан да күбрәк балалары (тәрбиягә алган балаларны кертеп) булган гаиләләрдән, гомуми белем бирү оешмасында көндезге уку формасында белем алучы өлкән баласы 18 яшькә яки 23 яшькә кадәрге булган гаиләләләрдән, 5-11 сыйныф укучыларын;
- Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды документы нигезендә җан башына уртача кереме бер кешегә яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдән, 5-11 сыйныф укучыларын;
- туберкулез йогышлы авыруыннан дәваланучы балаларны.»

1.2. Тәртинең 2.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Түбәндәге балаларны ике тапкыр түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итәргә:
- өлешчә мобилизация яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

ярдәм турында контракт төзегән гражданнарның (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) балаларын;

- хәрби хезмәткәрләр, әгәр хәрби хезмәт узу чорында яки аннан эштән китү яки контракт туктатылганнан соң аларга имгәнү (яралану, травма, контузия) аркасында инвалидлык билгеләнгән яки авыру алынган булса, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнарның балаларын;

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларны.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучы балаларның статусы психологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан билгеләнә, инвалид (инвалид бала) статусын медик-социаль экспертиза бюросы бирә.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чиклеукучыларга, өйдә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче (алга таба-өйдә укучыларга) инвалид балаларга азык - төлек җыелмасы рәвешендә ике тапкыр түләүсез туклану бирергә яисә аны ике тапкыр туклану бәясенә тиң акчалата компенсация белән тәэмин итәргә.

Укучыларны ике тапкыр түләүсез туклandыруны түбәндәге тәртиптә оештырырга:

иртәнге аш - уку дәресләре вакытында;

төшке аш - озайтылган көн төркемнәре белән берлектә.»

1.3. Тәртинең 2.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Ата-аналары Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия хезмәткәрләре булган 5-11 сыйныф укучылары өчен туклану бәясен бер укучыга көненә бер тапкыр кулланыла торган кайнар туклануның уртача бәясеннән 50% күләмендә билгеләргә.

Ташлама Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия бүлегенең бу айның 10 числосына кадәр Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә ай саен җибәрелә торган хезмәткәрләре реестрлары нигезендә бирелә.»

1.4.Тәртинең 3.3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. түбәндәге исемлек нигезендә ата-аналардан (законлы в әкилләрдән) документлар кабул итү эшен оештыру:

а) дүрт һәм һәм аннан да күбрәк балалары (тәрбиягә алган балаларны кертеп) булган гаиләләрдән, гомуми белем бирү оешмасында көндезге уку формасында белем алучы өлкән баласы 18 яшькә яки 23 яшькә кадәрге булган гаиләләләрдән, 5-11 сыйныф укучыларына;

- түләүсез кайнар ризык белән туклануга гариза;

- күпбалалы гаилә статусын билгеләү турындагы карарның күчермәсе йә балаларның туу турында таныклыклары;

- гомуми белем бирү оешмасында көндезге уку формасында белем алучы 18 яшькә яки 23 яшькә кадәрге балаларның белем алуы турында белешмә;

- уллыкка-кызлыкка алу өчен кирәкле документлар, ата булуны билгеләү турындагы таныклык, баланы опекага алу турындагы карар;

б) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларга, инвалид балаларга:

- түләүсез кайнар ризык белән туклануга гариза;
- инвалидлыкны раслаучы белешмәнең күчермәсе;
- психология-медицина-педагогика комиссиясе бәяләмәсе күчермәсе;

в) ата-аналары Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия хезмәткәрләре гаиләләреннән булган балаларга:

- ташламалы кайнар ризык белән туклануга гариза;

г) өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән гражданнарның балаларына (алга таба-хәрби хезмәткәрләр):

- түләүсез кайнар ризык белән туклануга гариза;

- ана/ата паспортының күчермәсе;
- баланың туу турындагы таныклыгының күчермәсе;
- уллыкка-кызлыкка алу өчен кирәкле документлар, ата булуын билгеләү турында таныклык, баланы опекага алу турында карар;
- атаның/ананың махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документның күчермәсе;
- никахлашу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатынның балалары бергә тәрбияләнгән очракта);

д) хәрби хезмәткәрләр, әгәр хәрби хезмәт узу чорында яки аннан эштән китү яки контракт туктатылганнан соң аларга имгәнү (гарипләнү) (яралану, травма, контузия) аркасында инвалидлык билгеләнгән яки авыру алынган булса, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булганнарның балалары:

- хәрби хезмәткәрнең имгәнү (яралану, травма, контузия) алу нәтиҗәсендә һәлак булуын (вафат булуын) раслаучы белешмәнең күчермәсе;

- хәрби хезмәткәрнең авыруы яки инвалидлыкта булуын раслаучы белешмә;
- хәрби хезмәткәрнең имгәнү (яралану, травма, контузия) алуы турында белешмә;

е) туберкулез йогышлы авыруыннан дәваланучы балаларга:

- табиб-белгечтән авыру турында белешмә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Р.Э. Әхмәдиева